| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>СОБОЛЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ<br>СОБОЛЕВСКИЙ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

04 .04.2018 — № 7

с. Соболевсое

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге торак пунктларын санитар-экологик чистарту икеайлыгы үткәрү турында

Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлегенең торак пунктлары территорияләрен төзекләндерү һәм санитар чистарту эшләрен оештыру һәм халыкның экологик иминлегенә җавап бирә торган эшләр башкару өчен;

Карар бирәм:

1. 2018 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Соболевский авыл җирлегенең торак пунктлары территорияләрен чистарту буенча санитар-экологик икеайлык игълан итәргә (алга таба - икеайлык)
2. Соболевский авыл җирлеген төзекләндерү комитеты составын 2021 елның 01 апреленнән 2021 елның 31 маена кадәр расларга ( 1 нче кушымта)
3. 2018 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр төзекләндерү чаралары планын расларга ( 2 нче кушымта).
4. Соболевский авыл җирлеге территориясендә урнашкан предприятие, оешма һәм учреждениеләр җитәкчеләренә, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, якындагы территорияләрне санитар чистарту эшен оештырырга тәкъдим итәргә.
5. Урыннарда агач һәм куаклар утырту эшен оештырырга, бинаның фасадларын ремонтларга.
6. Авыл җирлеге территориясендә күчемсез милеккә ия булган гражданнарга нинди хокукларга ия булуларына карамастан, үзләренең йорт яны территорияләрен санитар чистарту буенча эш алып баруны тәкъдим итәргә.
7. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә. Югары Ослан муниципаль районының мәгълүмат сайтында урнаштырырга.
8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы — О.Н.Майорова

Югары Ослан  муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге
Башкарма комитетының
02.04.2018 ел,  № 7 карарына
1нче кушымта

Соболевский  авыл җирлеге төзекләндерү буенча комитет составы

1. Майорова Ольга Николаевна -  Соболевский авыл җирлеге башлыгы
2. Сёмина Екатерина Николаевна - Башкарма комитет секретаре
3. Фёдоров Николай Алексеевич - Чулпаниха 7 нче  сайлау округ депутаты
4. Росихина Людмила Ивановна -   Карамыш 4 нче  сайлау округ депутаты
5. Якимова Любовь Александровна - Соболевский авыл Мәдәният йорты мөдире

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы                                        О. Н. Майорова

Соболевский авыл җирлеге
Башкарма комитетының
02.04.2018 ел, № 7 карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрен санитар чистарту чаралары
Планы

| № | Чараның атамасы | Үткәрү датасы | Башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1. | Гражданнар җыелышларын, Авыл җирлеген төзекләндерү мәсьәләсе буенча Совет утырышын үткәрергә | 02.04.2018 | Авыл җирлеге башлыгы, җирлек халкы |
| 2. | Каты көнкүреш калдыкларына дача хуҗалыклары белән шартнамәләр төзергә.<br>Юл буе полосаларын чистарту бердәм санитария көне - чәршәмбе | 01.05.2018 елдан<br><br>01.04. 2018 дән 31.05.2018 кадәр | А. Цветков.<br><br>Авыл җирлеге башлыгы, учреждение, оешмалар җитәкчеләре |
| 3. | Якын-тирәдәге территорияләрдә санитар нормаларның үтәлешен системалы рәвештә тикшерергә һәм оештырырга. | даими | Авыл җирлеге башлыгы, участок полициясе вәкиле |
| 4. | ТР санитария һәм табигатьне саклау законнарын бозуларны ачыклау һәм кисәтү буенча полициянең участок вәкаләтле вәкиле белән берлектә рейдлар уздырырга | Атнага 1 тапкыр | Авыл җирлеге башлыгы, участок полициясе вәкиле |
| 5. | Торак пунктлар эчендә юл буе полосаларын җыештыру һәм баганаларны буяу | 20.04.2018дән 25.04.2018 кадәр | Авыл җирлеге башлыгы, учреждение, оешмалар җитәкчеләре |
| 6. | Авыл җирлеге территориясендә урнашкан учреждениеләрнең, оешмаларның фасадларын ремонтлау | 01.05.2018дән 31.05.2018 кадәр | учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләре, |
| 7. | Йортларның фасадларын ремонтлау | 01.04. 2018дән 31.05.2018 кадәр | Авыл җирлеге территориясендә торак урыннар милекчеләре, яллаучылар |
| 8. | Соболевский авылында һәм Чулпаниха авылында һәйкәлләрне төзекләндерү. Чәчәкләр утырту. | 2018елның 1 маена кадәр. | Башкарма комитет һәм мәдәният хезмәткәрләре |
| 9. | Авыл җирлеге территориясендә урнашкан зиратларны төзекләндерү | 01.05.2018дән 31.05.2018 кадәр | Авыл җирлеге башлыгы, учреждение, оешмалар җитәкчеләре , халык. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10. | Авыл җирлеге территориясендә чишмәләрне төзекләндерү | даими | Авыл җирлеге башлыгы, учреждение, оешмалар җитәкчеләре , халык. |
| 11. | Авыл җирлегенең торак пунктларында яшел үсентеләр утырту. Чәчәкләр утырту. | 01.05.2018дән 31.05.2018 кадәр | Авыл җирлеге башлыгы, учреждение, оешмалар җитәкчеләре , халык. |
| 12. | Су җыю башняларын төзекләндерү | 01.04. 2018дән 31.05.2018 кадәр | Авыл җирлеге башлыгы |
| 13. | Җирлек эчендәге юлларны ремонтлау (грейдирлау, чокыр ремонты) | 15.04. 2018дән 31.05.2018 кадәр | Авыл җирлеге башлыгы, предприятие җитәкчеләре |
| 14. | Янгынга каршы таләпләрне һәм төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү буенча комиссияләр каравын үткәрү | даими | Төзекләндерү комитеты |

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы О.Н.Майорова